**Карар № 99**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Кышлау авыл җирлеге Советы**

Кышлау авылы 28 май 2024 ел

**Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында " 2023 елның 10 июлендәге 286-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Уставына таянып, Кышлау авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Әтнә муниципаль районы Кышлау авыл җирлеге Советының 2017 елның 31 июлендәге 52 номерлы карары белән расланган Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үз хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 14 пунктның 1-2 абзацларында «йә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан белә торып тулы булмаган белешмәләр бирү йә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 14 пунктның 3 абзацында «яисә, федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр бирү» сүзләрен «, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, алдан ук тулы булмаган белешмәләр тапшыру яисә белә торып дөрес булмаган белешмәләр тапшыру» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (www.atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Кышлау авыл җирлеге башлыгы: Кашшапов А.Х.

Совет Кшкловского сельского поселения
Кышлау авыл җирлеге Советы
ИНН 1610000620